СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**29.03.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 286**

«Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2017 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабы хакында

«Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе Д. А. Сапожниковның «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2017 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы докладын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы билгеләп үткәнчә, «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы турында» нигезләмәгә таянып эш итте

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Советы депутатларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2017 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын исәпкә алырга (кушымта итеп бирелә).
2. 2017 ел өчен «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең эшен канәгатьләнерлек дип танырга.
3. «Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2017 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырырга

**Зеленодольск**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе А.В. Тыгин**